# Йомры-икмәкнең серле урманга сәяхәте.

**Авторлар: муз.җитәкчесе Симаева С.Ш.,**
**татар теле укытучесе Зарипова А.Д.**

**Казань 2017ел**

Бабай чыга,өй алдында йөри.

**Бабай** *(әби янына килеп)***:**

Кара монда карчык,-үзең яхшы беләсең,хәлләр авыр;

Китсен бездән Кәҗә белән Сарык,

Ашап ята бушка гына алар азык.

**Әби:** Китсен бездән Кәҗә белән Сарык,

Аларны асраудан ни файда бар?

**Сарык:** Кәҗә,син ишеттеңме?

Әби белән бабай картайдылар

Безне асрарга хәлләре юк.

**Кәҗә:** Сарык, дус**,** ни хәл итик?

**Сарык:** Әйдә урманга китик...

Бабайга да кирәкмибез

Әбигә дә кирәкмибез. (китәләр)

**Бабай:** Карчык, чык әле ишек алдына
Кәҗә, сарык юк монда.

**Әби:** Бабай, алар безнең сөйләшүне ишеткәннәр,
Җыелышып, үпкәләп урманга юл алганнар. Нишләрбез икән?

**Бабай:** Картаябыз инде, карчык.

Ялгыз гына икебез,

Боегып, ике почмакта

Утырырбыз инде без.

Ничек шәп булыр иде дә.

Әгәр шунда бер малай

順ыбызда уйнап йөрсә:

- Әби, - диеп, - я бабай.

(Әби дә башын күтәрә, уфтанып куя.)

**Әби.** И атасы, үзем дә гел

Шул уйны уйлап йөрим,

Әллә соң сиңа камырдан

Кабартма ясап бирим? (Бабайга карап.)

Бар әле, атасы, он кертеп бир әле. ( Бабай чыгып китә, савыт белән он күтәреп керә.)

**Бабай.** Савытларның төбен кырдым,

Соңгы онны алып кердем.

Мә, әбисе, үзең кара.

Ни генә пешерерсең. ( Әби онны ала, җырлый-җырлый, камыр баса башлый.)

**Әби.** Аклы ситса яулыгымны
Ап-ак итеп бәйләдем.
Ай камырым, кабарып пеш,
Булырсың йомры-йомшагым.

**Әби.** Кызарып кына пешкәнсең,
Үзең шундый йомры-йомшак.
Тәрәзә төбенә куям,
Китә күрмә тәгәрәп.

**Йомры- икмәк (**җырлый**)** Мин – йомры-икмәк , мин йомры-икмәк
Тәгәрәп йөри алам.
Тик әби-бабай өендә
Озак утыра алмам.
Мин бик матур, мин бик матур ,
Качыйм әле тәгәрәп.

**Бабай** чыга: Тукта әле йомры икмәк, качма әле тәгәрәп.
Син мине тыңла!
Сарык белән кәҗә, урманга киттеләр.
Карчык белән безгә упкәләделәр.
Синең дусларың күп урманда,
Сарык белән кәҗәне,
Син булыш!
Кайтар өйгә!

**Йомры- икмәк.** (җырлый –җырлый урманда чаба)

Мин – йомры-икмәк, мин йомры- икмәк,
Күрми калды әбием,
Бабай бирде йөкләмә,
Сарык белән кәҗәне серле урманнан табырга.
Берүзем бу урманда,
Һичкем юк бу аланда.

**“Танец русалок”**

**Су анасы:** Ничек һичкем булмасын,
Мине кая куясың?
Мин урмандагы күлнең хужасы.
Алтын таракның иясе.
Сине күрәм беренче тапкыр
Син үзең кем буласың?

**Йомры- икмәк (**жырлый**).**

Мин – йомры- икмәк мин йомры- икмәк,
Күрми калды әбием,
Бабай бирде йөкләмә,
Сарык белән кәҗәне серле урманнан табырга.
Су –анасы, син Сарык белән кәҗәне күрмәдеңме?

**Су анасы:** Күрдем сарык белән кәҗәне**,**
Мин сорау бирәм,
Дөрес җавап бирсәң
Юлны сиңа күрсәтәм.

1.Шурәлене кем алдаган?(Былтыр)

2.Алтын таракның хуҗасы кем?

3.Күбәләк кем белән сөйләшкән?

**Йомры- икмәк.** Рәхмәт сиңа, Су анасы.

**Йомры- икмәк (**жырлый**).** Мин – йомры- икмәк, мин йомры- икмәк,
Күрми калды әбием,
Бабай бирде йөкләмә,
Сарык белән кәҗәне серле урманан тобырга.
Берүзем бу урманда,
Һичкем юк бу аланда.

**Шурәле чыга:** Нинди чыелдык монда,
Йокымны бүлеп йөри?
Вакыт килде уйнарга,сине кытыкларга.
Ә,син кем буласың?
**Йомры- икмәк (**жырлый**).** Мин – йомры- икмәк, мин йомры- икмәк,
Күрми калды әбием,
Бабай бирде йөкләмә,
Сарык белән кәҗәне серле урманнан табырга.
Син үзең кем буласың?

**“Шүрәлеләр биюе “**

**Йомры-йомшак:**Шүрәле,эй шүрәле, син кытыклама мине ,
Сарык белән кәҗәне күрмәдеңме,әйт әле?

**Шүрәле ;** Күрдем сарык белән кәҗәне**,**
Аларның дусты- соры буре

Безнеӊ белән уйнасаӊ
Юлны тиздән күрсәтәм.

**“Шүрәлеләр белән уен”**

**Йомры- икмәк.** Рәхмәт сиңа, Шүрәле

**Йомры- икмәк (**җырлый**).** Мин – йомры- икмәк, мин йомры- икмәк,
Күрми калды әбием,
Бабай бирде йөкләмә,
Сарык белән кәҗәне серле урманнан табырга.
Берүзем бу урманда,
Һичкем юк бу аланда.

**Сертотмас урдәк:**
Вак- вак, вак, чабам ,чабам,
Бөтен якка хабәр таратам.
Кәҗә белән сарык урманга качкан,
Бүреләр белән дуслашкан.
Әби белән бабай ялгыз калган!Вак,вак,вак!

**Йомры- икмәк.**Тукта әле,тукта әле.
Син кем буласыӊ?
Каян бөтенесен беләсеӊ?

**Сертотмас урдәк:** Мин җырларга яратам**,**
Урманны яңгыратам.
Тавышым еракка китер
Мине дуслар ишетер!

**“Дуслар җыры”**

Рәфис Корбан суз. Фуат Әбүбәкиров муз. **(**геройлар барысы чыгалар)

**Кәҗә:** Кичер мине, бабай.
**Бабай:** Кичер мине, Кәҗә.
**Сарык:** Кичер мине, әби.
**Әби:** Кичер мине,сарык

**Бөтенесе бергә:**

Авырлык артта калды!
Дуслык барын да җинде!

В спектакле используется музыка Ф Яруллина из балета “Шурале” ,
Анвара Бакирова «Су анасы» .